ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.02.2020 ел Баулы шәһәре № 28

2020-2022 елларга Татарстан
Республикасы Баулы муниципаль
районының инвестиция меморандумы
турындагы нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020-2022 елларга Татарстан Республикасының инвестиция меморандумын раслау турында» 2019 елның 20 декабрендәге 1178 номерлы карары нигезендә, Баулы муниципаль районында инвестиция эшчәнлегендә катнашучыларның үзара хезмәттәшлегенең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Кумта итеп бирелгән 2020-2022 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының инвестиция меморандумы турындагы нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче И.И. Гозәеров

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 02.10. №28 номрлы
карары белән расланган

**2020-2022 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Инвестицион меморандумы турында нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Инвестицион меморандумы (алга таба – Меморандум) Баулы муниципаль районында инвестицион эшчәнлек үсешенең төп өстенлекләрен билгели.

1.2. Әлеге Меморандум нигезләмәләрен гамәлгә ашыру өчен җаваплылык үзәге булып Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – Координатор) тора.

1.3. Меморандум Баулы муниципаль районының стратегик максатын тормышка ашыруга – киләчәк икътисады, белем икътисады нигезләрен (контурларын) формалаштыруга юнәлдерелгән, ягъни ул икътисад тотрыклы үсеше нигезендә халыкның тормыш сыйфатын алга таба дөнья стандартлары дәрәҗәсенә кадәр күтәрергә мөмкинлек биререгә тиеш.

1.4. Меморандум инвестицион эшчәнлек субъектлары тарафыннан Инвестиция эшчәнлеге планнарын эшләү һәм раслау өчен нигез буларак тәкъдим ителде.

1.5. Баулы муниципаль районы икътисадына инвестицияләр җәлеп итү мәсьәләләре буенча коллегиаль киңәшмә органы - Баулы муниципаль районының Инвестицион советы.

1.6. Меморандум нигезләмәләрен үтәү мониторингы Координатор тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## 2. Инвестицион сәясәтнең төп юнәлешләре

2.1. 2020 елда Баулы муниципаль районының инвестицион сәясәтенең төп юнәлешләре булып торалар:

районда уңай инвестицион климат формалаштыру;

инвестицион эшчәнлек инфраструктурасын үстерү;

инвестиция эшчәнлегенә дәүләт ярдәме чараларын һәм дәүләт заказлары системасын куллануның нәтиҗәлелеген арттыру;

фәнни нигезле югары технологияле тармакларга инвестицияләр агымын күбрәк юнәлтү буенча чараларны арттыру;

инвестицион эшчәнлеккә мәгълүмати ярдәм, белгечләр ярдәме;

икътисадка федераль һәм региональ инвестиция ресурсларын җәлеп итү;

алдынгы технологияләрне кулланучы конкурентлыкка сәләтле производстволарны формалаштыру һәм үстерү;

хезмәт җитештерүчәнлеген үстерүгә юнәлдерелгән проектларны гамәлгә ашыручы предприятиеләргә ярдәм күрсәтү;

инвесторларны җәлеп итү һәм алар тарафыннан тормышка ашырыла торган халыкның тормыш сыйфатын яхшыртуга һәм чит илдән кертелә торган продукцияне (эшләр, хезмәт күрсәтүләрне) алыштыруга юнәлдерелгән өстенлекле инвестицион проектларга ярдәм итү;

районда аларны гамәлгә кертү өчен, перспективалы үзебезнең технологияләргә ярдәм итү;

икътисадның реаль секторына, бигрәк тә югары технологияле өлкәләргә, аерым алганда, районда индустриаль сәнәгать мәйданчыклары булдыру юлы белән, кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә стимул бирү;

чимал базасын үстерү һәм ресурслардан файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру;

бюджет чыгымнарын оптимальләштерү;

эшчәнлекнең барлык өлкәләрендә эшләүчеләрнең хезмәт хакын арттыру өчен шартлар тудыру;

социаль-мәдәни өлкәне үстерү һәм уңай яшәү мохитен формалаштыру юлы белән район халкының тормыш сыйфатын күтәрү;

гамәлдәге салым законнары кысаларында товар җитештерүчеләргә салым ташламалары һәм инвестиция салым кредитлары рәвешендә дәүләт ярдәме;

предприятиеләрнең һәм оешмаларның инвестицион җәлеп итүчәнлеген арттыру өчен шартлар тудыру;

энергетика секторы эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру;

инвестицион проектларны гамәлгә ашырганда дәүләт-хосусый партнерлыкны үстерү, шул исәптән территорияләрнең инфраструктурасын үстерүгә, коммуналь челтәрләрне яңартуга, заманча ресурсларны саклау технологияләрен кертүгә юнәлдерелгән;

икътисадый үсешнең потенциаль нокталары булган тармакларга ярдәм итү:

агросәнәгать комплексы үсеше;

азык-төлек сәнәгатен үстерү;

төзелеш материаллары җитештерү;

җиңел сәнәгать үсеше.

2.2. Әлеге Нигезләмә белән билгеләнә торган инвестицион сәясәт юнәлешләренә, муниципаль районның социаль-икътисадый үсешенең нәтиҗәләрен һәм яңа өстенлекләрен исәпкә алып, шулай ук законнардагы үзгәрешләрне исәпкә алып, төзәтмәләр кертелергә мөмкин.

3. Инвестиция эшчәнлеге субъектлары

Инвестицион эшчәнлек субъектлары булып физик һәм юридик затлар, шул исәптән чит илнекеләр, шулай ук инвесторлар, заказчылар, подрядчылар, инвестицион эшчәнлек объектларыннан файдаланучылар һәм муниципаль районның сәнәгать мәйданчыклары территориясендә инвестицион эшчәнлек алып баручы башка катнашучылар була ала.

4. Инвестиция эшчәнлеге субъектларының үзара хезмәттәшлеге

Инвестиция эшчәнлеге субъектларының үзара хезмәттәшлеге тәртибе гамәлдәге закон кысаларында билгеләнә һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары тарафыннан Россия Федерациясенең халыкара килешүләре,

федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары нигезендә эшләнә торган регламентлар белән билгеләнә.

5. Баулы муниципаль районында
җирле үзидарә органнары бурычлары

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында җирле үзидарә органнарының әлеге Нигезләмә белән билгеләнә торган төп бурычлары булып торалар:

Үз компетенцияләре кысаларында, районда инвестицион климатны яхшыртуга юнәлдерелгән «юл карталарын» кертүне тәэмин итү;

Ел саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм муниципаль берәмлекләр арасындагы килешүләрдә билгеләнә торган халыкның тормыш сыйфатын күтәрү буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторларының пландагы күрсәткечләренә ирешү;

өстенлекле инвестицион проектларны тормышка ашыру мониторингы;

җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тарафыннан икътисадның реаль секторына инвестиция ресурсларын җәлеп итүнең нәтиҗәле механизмнарын формалаштыру.

6. Өстенлекле инвестицион проектлар

2020 елда гамәлгә ашыру өчен өстенлекле проектлар:

Кече бизнес:

нефть чыгару, нефть эшкәртү, кичекмәстән, торак-коммуналь хуҗалык һәм азык-төлек сәнәгате предприятиеләре өчен төрле комплектацияләрдә су үзгәрткечләрен ("пар ясау ысулы һәм җайланмасы" уйланмасы) эшләү һәм әзерләү ("Спецпрогресс" ҖЧҖ)»;

Этилацетат, коры азык чүпрәсе, азык-төлек углекислотасы эшләп чыгару («Александровка спирт заводы» ҖЧҖ);

6 мең тонна сыйдырышлы мини элеватор төзелеше («Баулы он комбинаты» ҖЧҖ);

терлек азыгы җитештерү цехы төзелеше ("Баулы он комбинаты" ҖЧҖдә);

склад биналарын киңәйтү, компаниянең фирма кибетләрен ачу, яңа продукт – «Кызыл эремчек» чыгару, яңа, герметик төргәкләрдә – күп катламлы пленка эремчек чыгару (“Садыйков Р. А.» КФХ «Сөт продукциясе җитештерү цехы»);

**Авыл хуҗалыгы:**

Силос-сенаж траншеялары төзү (Потап-Томбарлы авылы «Березовские зори» ҖЧҖ, Татар Томбарлы авылы «Берлек» ҖЧҖ);

сыер абзарын капиталь ремонтлау (Исергәп авылының «Бәкер» КФХ, Потап-Томбарлы авылының «Березовские зори» ҖЧҖ, Татар Томбарлы авылы «Берлек» ҖЧҖ);

яшелчә саклау бинасын капиталь ремонтлау (Мортаза авылы «Кыямова Г. А.» КФХ,);

ындыр табакларын капиталь ремонтлау (Татар Томбарлы авылы «Берлек» ҖЧҖ, Кырымсарай авылы «Кырымсарай» ҖЧҖ, Потап-Томбарлы авылы «Хаҗиев» КФХ);

машина-трактор паркларына капиталь ремонт ясау (Кырымсарай авылы «Кырымсарай» ҖЧҖ, Потап-Томбарлы авылы «Хаҗиев» КФХ);

ветеринария хезмәте бинасына капиталь ремонт, ветеринария берләшмәләренә һәм Баулы муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе бинасына капиталь ремонт;

**Социаль проектлар:**

ФАПлар төзү һәм сәламәтлек саклау объектларын капиталь ремонтлау (Фоминовка авылында ФАП);

модульле чаңгы базалары һәм универсаль спорт мәйданчыклары төзелеше (Татар Томбарлы авылында спорт мәйданчыгы);

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фондының «Социаль ипотека» программасы буенча күп фатирлы йортлар төзү (Баулы шәһәре, Гоголь урамы, 7 йорт (32 фатирлы);

Күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау (Баулы ш.: Гоголь ур., 6, Горюнов ур., 7, Горюнов ур., 8, Ленин ур., 26, Чапаев ур., 23, Новозареченски б.: Совет ур., 4; Поповка авылы, Үзәк ур., 12);

«Заманча мәктәп» федераль проекты кысаларында функциональ зоналарга капиталь ремонт(«6нчы гомумбелем мәктәбе» МББУ);

яшүсмерләр клублары челтәрен капиталь ремонтлау ("ПЕГАС" спорт-патриотик юнәлештәге яшүсмерләр клубы);

мәгариф объектларын – балалар белем бирү учреждениеләрен капиталь ремонтлау («Рябинка» 2нче балалар бакчасы ММББУ);

эш бирүчеләренең кадрларга ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен ресурс үзәкләрен капиталь ремонтлау(Баулы аграр көллияте);

мәдәни билгеләнештәге объектларны капиталь ремонтлау (Кырымсарай мәдәният йорты);

социаль билгеләнештәге объектларда котельныйларны ремонтлау («Кызылъяр урта мәктәбе» МББУ, «Алексеевски төп гомуми белем бирү мәктәбе» МББУ);

халыкны эчә торган су белән тәэмин итү (Кызылъяр авылы, проект-тикшеренү эшләре, Уд. Ташлы авылы, төзү-монтаж эшләре, Шәмәй авылы, төзү-монтаж эшләре);

урам утларын торгызу эшләре (Татар Кандызы, Ваешур, Покровский Урыстамак, Яңа Чүте, Хәнсевәр, Кырымсарай авыллары).

## 7. Өстенлекле программалар исемлеге

Баулы муниципаль районында финанслау һәм тормышка ашыру өчен тәкъдим ителгән өстенлекле программалары:

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2009 елның 11 мартындагы 58 номерлы карары белән расланган «2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасы;

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 18 ноябрендәге 321 карары белән расланган «2020 елга Баулы муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль программасы;

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган "2017-2020 елларга Баулы муниципаль районында мәдәниятне үстерү" муниципаль программасы;

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 17 маендагы 144 номерлы карары белән расланган «2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында авыл яшьләре» район программасы;

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 27 февралендәге №47 номерлы карары белән расланган (Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 18 июлендәге 214 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) 2019 елга Баулы муниципаль районының җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре программасы;

Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2016 елның 18 маенда кабул ителгән 149 номерлы карары белән расланган "2016-2020 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында энергияне сак тоту һәм энергия нәтиҗәлелеген арттыру" муниципаль программасы;

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 4 мартындагы 48 номерлы карары белән расланган «2016-2020 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» максатчан программасы;

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 18 маенда кабул ителгән 151 номерлы карары белән расланган “2015-2020 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру” муниципаль программасы;

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 22 октябрендәге 407 номерлы карары белән расланган 2019-2021 елларга

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту программасы;

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 17 маендагы 145 номерлы карары белән расланган «2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында яшьләргә патриотик тәрбия бирү» район программасы.